Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлеге Зәй-Каратай торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлеге Зәй-Каратай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, буенча теркәлгән, балачактан инвалидлар, шулай ук 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы хәрби хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:
(килешү буенча түләү) Зәй-Каратай торак пунктында җәй көне кул белән үлән чабу Зәй-Каратай авылы территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү.

2) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- Зәй-Каратай торак пунктында сууткәргечләр өзелүен бетерү;
- Зәй-Каратай торак пунктында су насосы һәм резервуар-накопительдә ремонт эшләре.

3) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
-Зәй-Каратай торак пунктында Вахит урамы, Дунай урамы, Яшьләр урамы, Озерная урамы, Пионер урамы, Подгорная урамы, Совет урамы буенча юлларны кардан чистарту; Уныш урамы, Якуп урамы.
Зәй-Каратай торак пунктында Пионер, Якуп урамнары буенча вак таш белән каплау җайланмасы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зәй - Каратай авылы, Совет урамы, 99 йорт, 1 корылма, Үзбәк авылы, Луговая урамы, 2 йорт буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы М.И.Идиятова